Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районының
Важашур авыл җирлеге Советы

КАРАР

23 сентябрь 2021 ел №18

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Яңил авыл җирлеге территориясендә гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм уздыру тәртибе турында Важашур авыл җирлеге Советының 2020 елның 28 гыйнварындагы 4 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына туры китерү максатларында Важашур авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Важашур авыл җирлеге территориясендә гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм уздыру тәртибе турында Важашур авыл җирлеге Советының 2020 елның 28 гыйнварындагы 4 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 3 статьяның 2 өлешендәге 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

5) генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне ызанлау проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карарлар проектлары, рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турындагы карарлар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару буенча расланган кагыйдәләр булмаганда, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның рөхсәт ителгән бер төрен икенче төргә үзгәртү мәсьәләләре буенча гавами тыңлаулар яисә иҗтимагый фикер алышулар шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә уздырыла;»

б) 6 статьяның 1 пунктында:

«гавами тыңлауларны билгеләү турында» сүзләреннән соң «гавами тыңлауларны үткәрү вакыты һәм урыны турында» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге статьяның 1 өлешендәге беренче абзацында күрсәтелгән материалларны һәм мәгълүматны урнаштыру, Муниципаль берәмлек кешеләренең муниципаль хокукый акт проекты буенча үз кисәтүләрен һәм тәкъдимнәрен бирү мөмкинлеген тәэмин итү өчен, шулай ук муниципаль берәмлек халкының гавами тыңлауларда мондый максатлар өчен рәсми сайттан мәҗбүри файдалану турындаталәпләрне үтәп катнашуы өчен Әлеге статья максатлары өчен, аннан файдалану тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы файдаланылырга мөмкин.».

в) 12 статьяда:

өченче абзацка «, әлеге статьяның дүртенче абзацында билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацтан соң тутыру түбәндәге эчтәлекле абзацны өстәргә:

«Территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителүгә бәйле рәвештә җирлекнең генераль планына үзгәрешләр әзерләнгән очракта, иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы П.Л.Иванов